КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 12 июль г.Казань № 568

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль әһәмияткә ия булган проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан конкурс нигезендә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 8 август, 565 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль әһәмияткә ия булган проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан конкурс нигезендә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 8 август, 565 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 24 июль, 587 нче; 2018 ел, 19 ноябрь, 1013 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Социаль әһәмияткә ия булган проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан конкурс нигезендә субсидияләр бирү тәртибендә:

13 нче пунктның 1 нче пунктчасындагы беренче абзацта «граждан җәмгыяте институтларын» сүзләреннән соң «һәм граждан инициативаларын» сүзләрен өстәргә;

16 нчы пунктта:

беренче абзацта «килешүләр» сүзләрен «субсидия бирү турында килешү» сүзләренә алыштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«чит ил юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталларында теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән салым салуның ташламалы салым режимы һәм (яки) финанс операцияләре үткәргәндә мондый юридик затларга мөнәсәбәттә мәгълүматны ачу яки бирү күздә тотылмаган дәүләт яки территория (офшор зоналар) булган чит ил юридик затлары өлеше гомумән алганда 50 проценттан артып киткән россия юридик заты булып тормау;

агымдагы финанс елында яки конкурс башланган көнгә бу Тәртип белән билгеләнгән максатлар өчен башка хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмау.»;

18 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Конкурста катнашу өчен вәкаләтле органга бу Тәртипкә теркәлгән кушымтада бирелгән форма буенча заявка тапшырыла, аңа түбәндәгеләр теркәлә:

коммерциягә карамаган оешма уставы күчермәләре;

коммерциягә карамаган оешма тарафыннан Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Коммерциягә карамаган оешмалар эшчәнлеген җайга сала торган федераль законнарның аерым нигезләмәләрен тормышка ашыру чаралары турында» 2006 елның 15 апрелендәге 212 номерлы карары нигезендә кертелгән үткән финанс чоры өчен хисап документлары күчермәсе;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында үз вакытында түләнмәгән башка бурычлары булмавын раслый торган һәм коммерциягә карамаган оешманың җитәкчесе һәм баш бухгалтеры имзасы куелган белешмә кәгазе;

коммерциягә карамаган оешманың җитәкчесе һәм баш бухгалтеры имзасы куелган агымдагы финанс елында яки конкурс башланган көнгә бу Тәртип белән билгеләнгән максатлар өчен башка хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмау турындагы белешмә кәгазе;

гамәлдәге лицензия күчермәләре (лицензияләнергә тиешле проект кысаларында эшчәнлек төрләре өчен);

теркәлгән һәм теркәлә торган барлык документларның исемнәре күрсәтелгән документлар исемлекләре.»;

19 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19. Бер коммерциягә карамаган оешма бары бер генә заявка бирә ала.

Заявка язма рәвештә, шулай ук Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталы (алга таба – Портал) аша электрон рәвештә тапшырылырга мөмкин.

Заявка бирү барышында тапшырыла торган барлык документлар, шул исәптән Портал аша бирелә торган документлар барлык пунктлар буенча төгәл басылган һәм тутырылган булырга тиеш (мәгълүматлар булмаган очракта, сызык куела). Бозып төзәтүләр һәм төзәтүләр (вәкаләтле затның мөһере сугылган һәм имзасы куелган төзәтүләрдән башка) рөхсәт ителми.

Кәгазь йөрткечтә бирелгән заявканың барлык битләре һәм аңа теркәлә торган документлар нумерланган, тегелгән һәм аларга вәкаләте булган затның имзасы куелган булырга тиеш, шулай ук теләсә нинди электрон йөрткечтә (doc/docx, xls/xlsx, pdf форматларында) кертелергә тиеш.

Кәгазь йөрткечтәге заявка һәм аңа теркәлә торган документлар турыдан-туры вәкаләтле органга тапшырыла яки аңа почта аша җибәрелә.

Электрон рәвештә бирелә торган заявка (техник мөмкинлек булганда) коммерциягә карамаган оешманың вәкаләтле затының (кодлар, парольләр яки башка чараларны кулланып, коммерциягә карамаган оешманың вәкаләтле заты тарафыннан электрон имза булдыру фактын раслый торган) гади электрон имзасы белән расланырга тиеш.»;

20 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. Заявканы кабул иткәндә вәкаләтле орган аны кергән көндә заявкаларны исәпкә алу журналында терки һәм коммерциягә карамаган оешмага, аны алу көнен һәм бирелгән теркәү номерын күрсәтеп, заявканы алу турында расписка бирә.

Заявка вәкаләтле органга почта аша кергәндә ул бер көн эчендә заявкаларны исәпкә алу журналында теркәлә. Бу очракта гариза алу турында расписка бирелми, заявкаларны исәпкә алу журналында теркәлү көне итеп почта аша җибәрелгән әйберне элемтә оешмасына почта аша җибәрелгән әйбергә басылган штемпель белән расланган тапшыру көне күрсәтелә.

Вәкаләтле органга электрон рәвештә кергән (техник мөмкинлек булганда) заявка кергән көнендә теркәлә.

Вәкаләтле органга заявкалар кабул итү вакыты тәмамланганнан соң (шул исәптән почта аша) кергән заявка теркәлми һәм конкурста катнашуга рөхсәт ителми.»;

21 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«21. Тапшырылган заявкалар вәкаләтле орган тарафыннан заявкаларны кабул итү көне тәмамланганнан соң эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә бу Тәртип белән билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәүгә тикшерелә.

Электрон рәвештә (техник мөмкинлек булганда) заявка тапшырган заявка бирүчеләргә тикшерү нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат Портал аша электрон рәвештә хәбәр ителә.

Тикшерелгән заявкалар эш көннәрендә исәпләнә торган 3 көн эчендә вәкаләтле орган тарафыннан конкурс комиссиясенә тапшырыла.»;

25 нче пунктның таблицасына түбәндәге эчтәлекле 5.5 нче юл өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «5.5. | Территориясендә заявка бирүче тарафыннан конкурска кертелә торган проектны карап тикшерү, раслау һәм аңа ярдәм күрсәтү турындагы проектны тормышка ашыру планлаштырыла торган муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органыннан һәм (яки) Татарстан Республикасы Дәүләт Советыннан тәкъдимнамә хаты | юк – 0,<br>әйе – 0»; |

34 нче пунктның икенче абзацында «субсидия бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турында хисап документлары кертү вакытлары һәм формалары,» сүзләреннән соң «агымдагы финанс елында субсидия алучы

тарафыннан субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмый калган өлешләрен кире кайтару очраклары,» сүзләрен өстәргә;

35 нче пунктның беренче абзацында «коммерциягә карамаган оешманың» сүзләреннән соң «субсидия алучы тарафыннан Россия кредит оешмасында ачылган» сүзләрен өстәргә;

1 нче кушымтаны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә;

әлеге карар белән расланган Социаль әһәмияткә ия булган проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан конкурс нигезендә субсидияләр бирү комиссиясе (алга таба – комиссия) составында:

комиссия составыннан А.Ф.Мөбәрәкшинны чыгарырга;

комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Татарстан Республикасының хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары Гадел Рәфикъ улы Мөбарәкшинны;

Граждан инициативаларына ярдәм күрсәтү үзәге җитәкчесе Юлия Сергеевна Манинаны (килешү буенча).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин